# КАРАР

**“15” ноябрь 2021 ел** **№ 5**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 15 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдеру белән килешәсезме:

- Материал сатып алу һәм зират коймаларын ремонтлау.
- Материал сатып алу һәм «Салават» чишмәсен ремонтлау.
- Урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.
- Рөхсәтсез чүплекне рекультивацияләү.
- Су кудыру скважинасына насос сатып алу (2 данә).
- Бульдозер һәм амкадор хезмәтенә түләү
- Центральная урамында авария арматуралары өчен тимер-бетон боҗралар куеп, суүткәргеч челтәренә олешчә ремонт ясау.
- Җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең машиналар йөрү өлешен тигезләү һәм түшәү өчен вак таш сатып алу:
  - Үзәк, С. Халиков, Мәктәп урамнары.
- Инеш аша салынган җәяүле куперне ремонтлау.

«ӘЙЕ» “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 372 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 195 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 195 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдеру белән килешәсезме:

- Материал сатып алу һәм зират коймаларын ремонтлау.
- Материал сатып алу һәм «Салават» чишмәсен ремонтлау.
- Урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.
- Рөхсәтсез чүплекне рекультивацияләү.
- Су кудыру скважинасына насос сатып алу (2 данә).
- Бульдозер һәм амкадор хезмәтенә түләү
- Центральная урамында авария арматуралары өчен тимер-бетон боҗралар куеп, сууткәргеч челтәренә олешчә ремонт ясау.
- Җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең машиналар йөрү өлешен тигезләү һәм түшәү өчен вак таш сатып алу:
  - Үзәк, С. Халиков, Мәктәп урамнары.
- Инеш аша салынган җәяүле куперне ремонтлау.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Иске Ашыт авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Фәйзуллин